## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**2023 елның 28 октябре** **№5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлеге Күгәй авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I, II төркем инвалидлардан (ялгыз яшәүчеләрдән), көндезге бүлектә укучы студентлардан, 3 елдан артык торак пункт территориясендә яшәмәгән кешеләрдән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- Аръяк урамындагы суүткәргечне алыштыру (сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3.Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең Интернет челтәрендәге порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык урамы, 20 йорт (мәдәният йорты бинасы) кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күгәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Хисаметдинова